# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Гали торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16.11. 2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Гали торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 16 ноябрендә 10:00 сәг.тә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районың «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Гали торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм irектән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 350 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, өстәмә җиһазлар (төягеч, чапкыч, тагылма) сатып алу.
2. Гали торак пунктында урамнарны яктырту өлешендә гамәлләр (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны сатып алу, урнаштыру һәм алмаштыру).
3. Гали торак пунктында су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосларын һәм материаллар ремонтлау, хезмәт күрсәтү, сатып алу.
4. Гали торак пунктындагы урамнарны кардан чистарту (ГСМ, май сатып алу).
5. Янгын автомашинасын карап тоту, ремонтлау, янгын автомашинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.
6. Гали торак пунктында хуҗасыз йортларны карап тоту, фасадларның тышкы ягын төзекләндерү (агач материаллар, торбалар, профильләр алу).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 31 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 18 кеше, бу 58 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 18 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Гали торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Гали торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 350 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, өстәмә җиһазлар (төягеч, чапкыч, тагылма) сатып алу.

2. Гали торак пунктында урамнарны яктырту өлешендә гамәлләр (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны сатып алу, урнаштыру һәм алмаштыру).

3. Гали торак пунктында су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосларын һәм материаллар ремонтлау, хезмәт күрсәтү, сатып алу.

4. Гали торак пунктындагы урамнарны кардан чистарту (ГСМ, май сатып алу).

5. Янгын автомашинасын карап тоту, ремонтлау, янгын автомашинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.

6. Гали торак пунктында хуҗасыз йортларны карап тоту, фасадларның тышкы ягын төзекләндерү (агач материаллар, торбалар, профильләр алу).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
авыл җирлеге Башлыгы Ф.М. ЙОСЫПОВ

Совет Девятерчинского сельского поселения
Девәтернә авыл җирлеге Советы